Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге составына керүче Суровка авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

«30» май 2026 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартында 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә гражданнар җыены

КАРАР БИРДЕ:

1. Үзгәрешләр кертергә:

1) түбәндәге редакциядә бәян итеп, гражданнар җыенына чыгарылган һәм кабул ителгән «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге составына керүче Суровка авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2025 елның 25 ноябрендәге 1 номерлы гражданнар җыены карарына:

« - торак пункт чикләрендә җирле билгеләнештәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Суровка авылында вак таш сатып алу);

«- урам яктырту эшләрен башкару (электроматериаллар сатып алу, Суровка авылында урамнарны яктырту челтәрләрен монтажлау һәм урнаштыру);

« - торак пунктның башка территорияләрен (Суровка авылындагы скверларны һәм халыкның ял итү урыннарын) төзекләндерү".

2) 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, 2025 елның 25 ноябрендәге 2 номерлы Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге Суровка авылында гражданнар җыены карарына:

« - торак пункт чикләрендә җирле билгеләнештәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Суровка авылында вак таш сатып алу);

«- урам яктырту эшләрен башкару (электроматериаллар сатып алу, Суровка авылында урамнарны яктырту челтәрләрен монтажлау һәм урнаштыру);

« - торак пунктның башка территорияләрен (Суровка авылындагы скверларны һәм халыкның ял итү урыннарын) төзекләндерү".

2. Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге Суровка авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

3. Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге Суровка авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Новотроицк авыл җирлеге Башлыгы Д.М. Габделхаева